РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ШЕМОРДАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422050, Республика Татарстан, Сабинский район, с. Шемордан, ул. Лермонтова, 2
тел. (84362) 3-21-44

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШЭМЭРДЭН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422050, Татарстан Республикасы, Саба районы, Шэмэрдэн авылы Лермонтов урамы, 2 йорт
тел. (84362) 3-21-44

e-mail: Shmd.Sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

03.06.2021 — № 38 - п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл башкарма комитеты тарафыннан 2017 елның 15 мартында кабул ителгән 15-п номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл башкарма комитеты тарафыннан расланган «Территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү турында, йә кызыксынган затларның территорияләрне планлаштыру буенча документлар әзерләү турындагы тәкъдимнәрен кире кагу турында Карар кабул итү " муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 30.12.2020 ел, № 509-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл башкарма комитеты

Карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл башкарма комитеты тарафыннан «Территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү турында, йә кызыксынган затларның территорияләрне планлаштыру буенча документлар әзерләү турындагы тәкъдимнәрен кире кагу турында Карар кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 15.03.2017 ел №15-п карары белән расланган “Территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү турында, йә кызыксынган затларның территорияләрне планлаштыру буенча документлар әзерләү турындагы тәкъдимнәрен кире кагу турында Карар кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 3 пунктта «аларны үтәү» сүзләрен «аларны үтәү, шул исәптән электрон формада административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү тәртибен үз эченә алган муниципаль хезмәт күрсәтү вариантлары, шул исәптән алар мөрәҗәгать иткән муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә карата да, шул исәптән, аларны алу өчен алар мөрәҗәгать иткән муниципаль хезмәт күрсәтүләргә карата да» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. 3 бүлектә 3.2.7 пунктының 3 абзацында түбәндәге эчтәлекле икенче җөмлә өстәргә: «дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 елешенең 2 пунктында күрсәтелгән документлар һәм мәгълүмат, аларны әзерләү өчен, мөрәҗәгать итү мизгелендә ведомствоара сорату нигезендә электрон рәвештә тапшырыла.».

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/shemordan адресы буенча, җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар, 1.2 пункттан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның 1.2 пункты 2022 елның 1 октябреннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз естемдә калдырам.

Шәмәрдән авыл җирлеге башлыгы А.Н.Гәрәев